**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы**
**Яңа Ибрай авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**
423079 Яңа Ибрай авылы
Совет урамы, 5 йорт
тел. (факс) 884344- 4-27-27

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Новоибрайкинского сельского поселения Аксубаевского муниципального района**
423079 с.Новое Ибрайкино
улица Советская, д.5

КАРАР

№ 19 2021 елның 02 июне

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында»
2019 елның 13 ноябрендәге 102 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

РФ Салым кодексының 397 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай районы прокуратурасының 2021 елның 1 февралендәге 02-08-02 номерлы протестын үтәү йөзеннән һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 13 ноябрендәге 102 номерлы карарына түбәндәге өстәмәләрне һәм үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Салым һәм салым буенча аванс түләүләрен түләү тәртибе» 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү җир кишәрлекләре урнашкан урын буенча җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 1/4 процент өлешенең тиешле салым ставкасының 1/4 күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.»

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 13 ноябрендәге 102 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 22 мартындагы 16 номерлы карары;

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Яна Ибрай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: http:// Aksubayevo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

СОВЕТ
НОВОИБРАЙКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлеге башлыгы.
Совет Рәисе Ф.Х.Кәбиров